| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЧУБУКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЧУБУКЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**18.12.2019г** **№18**

**Муниципаль преференцияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге башкарма комитеты

карар бирә:

1. Муниципаль преференцияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Н. Гадершин**